**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2024-2025 нче уку елы 6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 60**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Тел алды тартыгын билгеләгез. **(2 балл)**
 1) [з]
 2) [к]
 3) [һ]
 4) [м]

2. [ō] авазы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) колын
2) вагон
3) олан
4) торак

3. Нечкә сузыклардан гына торган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Әдәп башы — тел.
2) Инсафлының теле саф.
3) Тел күңелнең көзгесе.
4) Татлы тел тимер капканы ачар.

4. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) эчтәлек
2) ничек
3) безнең
4) китапта

5. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Ябыну өчен ике тукыма арасына мамык яки шуңа охшаш нәрсә куеп, сырып ясалган урын-җир.*
1) юрган
2) мендәр
3) киез
4) палас

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
 *Бауның озыны,*

1) сүзнең кыскасы яхшы.
2) эшнең кыскасы яхшы.
3) сүзнең дә озыны яхшы.
4) эшнең дә күплеге яхшы.

7. Җөмләдәге фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
*Скрипкә тавышы килгән якка колагын салып бераз уйланып утырды.* (Г. Бәширов)
1) куркып
2) тыңлап
3) уйланып
4) тырышып

8. Җөмләдәге омонимның төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Печән чабарга чык,*
*Кибеп беткәнче чык.*
1) саф
2) омоформа
3) омографлар
4) омофон

9. Җөмләдәге алмашлыкның төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**
*Бик сагындым синең шифалы суларыңны*. (Ф.Шәфигуллин)
1) күрсәтү
2) зат
3) билгеләү
4) юклык

10. Җөмләдә рәвешнең нинди җөмлә кисәге булуын билгеләгез. **(2 балл)**
*Әниемнең көмештәй чәчләрен яратам.*
1) аергыч
2) хәл
3) хәбәр
4) тәмамлык

## II. Теоретик бирем.

Иҗек турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**7 балл**)

___

___

___

___

___

___

___

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Сүз һәм аның ясалышын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) көнбагыш | 1) тамыр сүз |
| Ә) пыяла | 2) ясалма сүз |
| Б) сиртмә койрык | 3) саф кушма сүз |
| В) ямьле | 4) тезмә сүз |
| Г) әйлән-бәйлән | 5) парлы |

**Җавап : ________________________**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Биологиядән “икеле” алуына һич тә үкенмәде Камил. Чөнки бу фәнне ул башкаларга караганда яхшырак белә. “Икеле” алуының сәбәбе дә көлке сыман: контроль эш дәфтәрен тапшырмаган. Эшен беренче булып (эшләгән / төгәлләгән / биргән) иде дә, янәшә партада утыручы Сәриянең (эшен / биремен / мисалын) эшли алмаганын күреп, укытучы сизмәгәндә генә, дәфтәрен аңа сузды. Дәрес бетеп, тәнәфескә кыңгырау шылтырагач, укытучы үзе (әйтеп / карап / йөреп) җыйды дәфтәрләрне. Минем дәфтәр Сәриядә дип (сөйләмәс / дәшмәс / әйтмәс) бит инде! (Д. *Гайнетдиновадан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)** Һәр җавапка 0,5 балл.

Яңа ел җитте! Яңа ел!
Кышы, Язы, Җә..., К...зе –
Бар...сы белән дә яңа ул.
Ә иске ел ерак китте.
Киткән чакта елап китте.
Ул соң ниләр алып китте,
Һәм н...ләр калдырып китте? (*Р. Гаташ*)

3. Шигырьдән антоним исем һәм сыйфатларны парлап күчереп алыгыз, сүз төркемнәрен күрсәтегез. **(6 балл)**

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

4.*Кыш* сүзенә 3тамырдаш сүз уйлап языгыз. **(6 балл)**

5. “Тиздән Яңа ел” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)